**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы**
**Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең**
**Кужак авылы**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№1** **19.11.2021**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең Кужак авылы халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары нигезендә 2021 елның 19 ноябрендә "Кужак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән I төркем инвалидларыннан, олы яшьтәге ялгыз гражданнар; вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар; уку йортларының көндезге бүлекләрендә укучы студентлар; хөкем ителгәннәр; авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан (СОП, янгыннан зыян күрүчеләр) тыш, Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең Кужак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда 300 сум күләмендә узара салым кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә тоту белән килешәсезме ?:

1) Кужак торак пунктының авыл эчендәге юлларны төзекләндерү (транспорт хезмәтләре, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Кужак торак пунктының урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү ( лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам утларына хезмәт күрсәтү);

3) Кужак авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, Өлкәннәр көне, 9 Май, инвалидлар көне, спорт ярышлары ) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;

4) Җәйге чорда Кужак торак пунктында территорияне чабу (Беларусь -320.4 маркалы тракторга ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү );

5) Кужак торак пунктында юлларны кардан чистарту (Беларусь -320.4 маркалы трактор өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

6) “Сарман” район гәҗитенә некрологлар бирү;

7) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру ( биек үскән агачларны кисү)

ӘЙЕ ЮК».

мәсьәләсе буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча җыен беркетмәсе төзелде.

2021 елның 19 ноябрендәге гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 146 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 74 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 74 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең Кужак авылында узган халык җыенын узган дип санарга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча: " Кужак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән I төркем инвалидларыннан, олы яшьтәге ялгыз гражданнар; вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар; уку йортларының көндезге бүлекләрендә укучы студентлар; хөкем ителгәннәр; авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан (СОП, янгыннан зыян күрүчеләр) тыш, Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең Кужак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда 300 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә тоту белән килешәсезме?:

1) Кужак торак пунктының авыл эчендәге юлларны төзекләндерү (транспорт хезмәтләре, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Кужак торак пунктының урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү ( лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам утларына хезмәт күрсәтү);

3) Кужак авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, Өлкәннәр көне, 9 Май, инвалидлар көне, спорт ярышлары ) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;

4) Җәйге чорда Кужак торак пунктында территорияне чабу (Беларусь -320.4 маркалы тракторга ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү );

5) Кужак торак пунктында юлларны кардан чистарту (Беларусь -320.4 маркалы трактор өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

6) "Сарман" район гәҗитенә некрологлар бирү

7) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру ( биек үскән агачларны кисү)

ӘЙЕ ЮК»

кабул ителгән карарны ( “әйе” – 74 тавыш, “юк” – 0 тавыш) кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында (http:// sarmanovo. tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башлыгы А.Н.Габдрахманов